# Иске һөнәрләр.
# Морҗа чистартучы-трубочист



# Аяк кием чистартучы - чистильщик обуви.




# Фонарьчы - фонарьщик.



# Су ташучы-водовоз.



Рәсемнәргә туры килгән мәкальне табып укы, мәгънәсен аңлат:




**Агач беленә җимешеннән, адәм беленә эшеннән.**
**Аз сөйлә, күп эшлә.**
**Акча беткәнгә кайгырма, эшең беткәнгә кайгыр.**
**Ашаганың белән мактанма, эшең белән мактан.**

***Җиде кат үлчә, бер кат кис.***
***Җимешне вакытында аша, эшне вакытында эшлә.***
***Җиңел эш бармак башында, авыр эш йөрәк башында.***









# *Син ризамы?*



Табиб укыта.
Бакчачы пешерә.
Биюче бии.
Тегүче сата.
Сатучы төзи.
Укытучы тегә.
Пешекче
дәвалый
Төзүче утырта.





.





Китапханәче … бирә.



Укытучы … укыта.



Тегүче … тегә.

Төзүче … төзи.



Сатучы … сата.



Пешекче … пешерә.

## *Сүзләр өстәп җөмләләрне дәфтәргә яз:*

- Китапханәче (нинди?)  бирә.
- Укытучы (нинди?)  укыта.
- Тегүче (нинди?)  тегә.
- Төзүче (нинди?)  төзи.
- Сатучы (нинди?)  сата.
- Пешекче (нинди?)  пешерә.

- (тәмле, кызыклы, зур, матур, тырыш, файдалы)